М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов

# Туган тел

## (ТАТАР ТЕЛЕ)

### 5 сыйныф

МЕТОДИК ӘСБАП

*Төп гомуми белем бирү оешмаларында*
*(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән)*
*эшләүче укытучылар өчен*

КАЗАН
2022

УДК 811.512.145 (075.2)
ББК 81.632.3я71
Ш92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтында эшләнде

**Шәкүрова, М. М.**

Ш92 Туган тел (татар теле). 5 сыйныф. Методик әсбап : төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен. / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 52 б.

Методик әсбапта 5 нче сыйныфта программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр, материалның эчтәлеге, предмет нәтиҗәләре бирелә, уку предметын үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы, дәреслек белән эшләү тәртибе аңлатыла. Тематик планда ике юнәлеш өчен булган фонетик, лексик, грамматик материал, укучыларның төп эшчәнлек төрләренә бәяләмә карала. Дәрес планнары үрнәкләре тәкъдим ителә.

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2022
© Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2022
© Шәкүрова М. М., Гыйниятуллина Л. М., Хисамов О. Р., 2022

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Укыту-методик комплекты татар телен туган тел буларак өйрәнә торган 5 нче сыйныф укучылары белән эшләүче укытучыларга тәкъдим ителә. УМК дәреслек, электрон дәреслек һәм укытучылар өчен методик әсбапны үз эченә ала.

Төп гомуми белем бирү оешмаларының 5 нче сыйныфы өчен «Туган тел (татар теле)» предметыннан УМК Федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә эшләнде. Ул яңа белемнәрне һәм күнекмәләрне мөстәкыйль үзләштерүгә нигез булып тора. УМК төп гомуми белем бирү дәрәҗәсендә регулятив, танып белү һәм коммуникатив универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга зур өлеш кертә.

5 нче сыйныфта «Туган тел (татар теле)» предметын укыту түбәндәге максатларны тормышка ашыруга юнәлтелә:

- укучыларда коммуникатив компетенция (үз хисләрен, фикерләрен һәм ихтыяҗларын белдерү өчен тел чараларыннан файдалану осталыклары һәм әзерлекләре) формалаштыру; Россия Федерациясе күпмилләтле халкының тел мирасын хөрмәт итүче шәхес тәрбияләү.

Куелган максат түбәндәге бурычларны үтәүне күздә тота:

- татар теле, аның төзелеше, стилистик чаралары, татар әдәби теле һәм сөйләм этикеты нормалары турында белемнәрне үзләштерү, сүз байлыгын һәм грамматик чараларны куллануның күләмен арттыру;
- сөйләм һәм фикер эшчәнлеген, төрле ситуацияләрдә татар телендә иркен аралашуны тәэмин итә торган коммуникатив осталыкларын, сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә ихтыяҗны үстерү;
- танып белү, анализ ясау, классификацияләү, аларны нормага һәм аралашу очрагына туры килү-килмәүкүзлегеннән чыгып бәяләү, төрле чыганаклардан, текстлардан мәгълүмат туплау тәҗрибәсе булдыру;
- укучыларда туган телгә (татар теленә) ихтирам һәм ярату хисләре, халыкның рухи хәзинәсе, милли кыйммәте буларак тел культурасы өчен җаваплылык тәрбияләү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү коммуникатив, лингвистик һәм социомәдәни компетенцияләр формалаштыру аша башкарылачак.

## 5 НЧЕ СЫЙНЫФ АХЫРЫНА ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ:

- монологның (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү) һәм диалогның (өндәү, фикер алышу, шәхесара мөнәсәбәтләрне билгеләү һәм җайга салу) төрләрен белү;
- текстның эчтәлеге буенча сораулар формалаштыру һәм аларга җавап бирү;
- дәрес материалы, үрнәк, терәк сүзләр, сораулар яисә планнан файдаланып, үз текстларын төзү;
- төрле функциональ-мәгънәви сөйләм төрләренә караган, тыңланган һәм укылган текстларның эчтәлеген аңлау;
- татарча текстларны аңлап, йөгерек һәм сәнгатьле итеп уку;
- төрле стиль һәм жанрлардагы текстларны уку, укуның төрле төрләрен белү (өйрәнү, танышу, карап чыгу);
- тел күнегүләрен (фонетик, лексик һәм грамматик) язмача башкару;
- текст төзү нормаларын (логикага нигезләнү, эзлеклелек, темага туры килү, бәйләнеш) саклап, үз фикерләрен телдән һәм язма формада ирекле, дөрес бәян итү;
- телдән һәм язма сөйләм төрләрен белү;
- «тел» һәм «сөйләм» төшенчәләрен, сөйләм төрләрен һәм сөйләм формаларын: диалог һәм монологны аера белү;
- сингармонизм законын белү: рәт һәм ирен гармониясен аеру;

- сузык һәм тартык авазларны тану;
- авазның мәгънәви функциясен аңлау;
- сөйләмнең аерым авазларын телдән һәм транскрипция элементлары ярдәмендә анализлау һәм характерлау;
- сүзләрне әйтү һәм язу үзенчәлекләрен белү;
- сөйләм аппаратының төзелешен аңлау;
- [э], [ц], [щ] авазларын, аларны язуда белдерә торган хәрефләрне дөрес куллану;
- ике аваз белдерә торган *е, ё, ю, я* хәрефләренең дөрес язылышын белү;
- ачык һәм ябык иҗекләрне билгеләү;
- басымлы иҗекне, логик басымны аеру;
- җөмләләрне дөрес төзү һәм тыныш билгесен интонация ярдәмендә аерып әйтү;
- боеру һәм тойгылы җөмләләрне тану;
- сүзгә фонетик анализ ясау;
- контексттан чыгып, сүзнең лексик мәгънәсен билгеләү;
- һөнәри лексиканы аера белү;
- сөйләмдә синонимнар, антонимнар, омонимнар (лексик омонимнар, омофоннар, омографлар, омоформалар) куллану;
- сөйләмдә фразеологизмнарны тану, аларның мәгънәсен билгеләү;
- тарихи, искергән сүзләрне, неологизмнарны (иң гади мисаллар) тану;
- алынмаларны һәм гомумтөрки сүзләрне аеру;
- алынма сүзләрнең тамырын, кушымчасын, нигезен аерып күрсәтү;

- форма ясагыч һәм сүз ясагыч кушымчаларны аеру;
- татар телендә сүз ясалыш ысулларын белү;
- сүзләргә морфемик һәм сүз ясалышы буенча анализ ясау;
- мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәрен билгеләү;
- исемнең гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү, аның сөйләмдәге ролен аңлату;
- тамыр, ясалма, кушма, парлы һәм тезмә исемнәрне тану;
- исемнәрдә тартым категориясен белү;
- сыйфатның гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү, аның сөйләмдәге ролен аңлату;
- сыйфатларның чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләрен ясау;
- тамыр, ясалма, кушма, парлы һәм тезмә сыйфатларны тану;
- алмашлыкның гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү;
- зат алмашлыкларының мәгънәсен һәм сөйләмдә кулланылышын белү;
- күрсәтү алмашлыкларын килешләр белән төрләндерү;
- микъдар, тәртип саннарының гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү;
- микъдар саннарының килеш белән төрләнеше турында белү;

- саннарның дөрес язылышын һәм ясалыш ысулларын (тамыр, кушма, парлы һәм тезмә) белү;
- хикәя фигыльнең гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү, аның сөйләмдәге ролен аңлату;
- фигыльнең заман формаларын белү;
- барлык һәм юклык формасындагы хәзерге, үткән (билгеле һәм билгесез) һәм киләчәк (билгеле һәм билгесез) заман фигыльләренең төрләнешен аеру;
- ярдәмче фигыльләрне сөйләмдә дөрес куллану;
- рәвешләрнең гомуми грамматик мәгънәсен билгеләү; сөйләмдә кулланылышын аңлату;
- рәвеш төркемчәләрен (урын, вакыт) тану;
- өйрәнелгән сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- бәйлекләрне һәм бәйлек сүзләрне аеру;
- бәйлекләрнең төрле килештәге сүзләр белән кулланылыш үзенчәлекләрен белү;
- кисәкчәләрне тану;
- кисәкчәләрнең дөрес язылышын белү;
- теркәгечләрне тану;
- тезүче теркәгечләрне аера белү;
- теркәгечләр белән җөмләләр төзи белү;
- җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аеру;
- тиңдәш кисәкләрне табу һәм мөстәкыйль рәвештә алар белән җөмләләр төзү;
- тиңдәш кисәкләре булган җөмләләрдә санау интонациясен куллану;
- җыйнак һәм җәенке җөмләләрне тану;
- җөмләдә баш кисәкләрнең белдерелүен аңлау;
- орфографик хаталарны билгеләү һәм аларны төзәтү;

- сөйләм культурасы, татар теленең сөйләм этикеты турында төшенчә формалаштыру;
- уку процессында һәм көнкүреш аралашу ситуацияләрендә сөйләм этикеты нормаларын үтәү;
- интонацияне саклау, тел чараларын дөрес сайлап алу, үз сөйләмен контрольдә тотуны булдыру.

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

### Дәреслекнең структурасы

Дәреслек ике кисәктән тора. Һәр кисәк ике зур теманы үз эченә ала. Беренче кисәктә «Мин» һәм «Тирә-як, көнкүреш» темалары, икенче кисәктә «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы» темалары урнаштырылды.

Дәреслек ике юнәлешне (база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләр) үз эченә ала. Туган телне тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган материал зәңгәрсу рамка белән ☐ бирелде. База өлешен өйрәнүче укучыларга да, балаларның белем дәрәҗәләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алып, әлеге биремнәр тәкъдим ителергә мөмкин. База һәм тирәнтен өйрәнү өчен булган материалның бер дәреслектә бирелүе көчлерәк укучылар белән аерым якын килеп эшләү мөмкинлеге тудыра.

Дәреслектә аерым тема эчендә ике юнәлеш өчен дә бер тексттан алынган берничә өзек кулланыла. Бу база өлешен өйрәнүче укучыларда текстның дәвамын уку теләге тудыру өчен дә отышлы.

**Темаларның төзелеше**

Һәр тема бертөрле калыпка салынды. Бер тема берничә дәресне үз эченә алырга мөмкин. Темаларның, дәресләрнең эчтәлеге түбәндәге тәртиптә эшләнде:

1) Дәрес гадәттәгечә психологик уңай халәт тудыру белән башланып китә. Укучылар ярдәме белән дәреснең темасы билгеләнә. Дәреснең максаты, бурычлары ачыклана.

2) Темага караган һәр дәрестә эпиграф белән эшләү (аерым әсәрләрдән алынган өзекләр, мәкальләр, табышмаклар һ.б.) дәресләрнең башлам өлешендә, йомгаклаганда, зур бер теманы тәмамлаганда мөстәкыйль фикер әйтергә, теманы ныгыту, нәтиҗә ясарга өйрәтү максатыннан кертелде.

3) Грамматик материал өйрәнелә.

4) Дәресләрнең үзәгендә текст белән эш тора. Сорауларга җавап бирү, рәсемнәр белән эшләү, фикер алышу (парларда эш), грамматик мәгълүматны ныгыту максатыннан башкарыла.

5) Дәреслектә яңа теманы ныгыту өчен биремнәр, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән бәйле эш төрләре тәкъдим ителә.

6) Теманы йомгаклау өчен күнегүләр, логик биремнәр, кызыклы эш төрләре бирелә. Чирек ахырында тестлар, кабатлау өчен сөйләм эшчәнлеге төрләре (ишетеп аңлау, уку, сөйләү, язу) белән бәйле күнегүләр, төрле биремнәр тәкъдим ителә.

## ПРЕДМЕТНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Татар телен белү дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә, һәр сыйныфның тематик материалы дүрт төп темага бүленә. Төрле төрдәге текст, аудио-, видео-, иллюстратив һәм график материалларны куллану күздә тотыла. Сораулар һәм биремнәр тәнкыйди фикерләүне үстерү-

гә, анализ, гомумиләштерү алымнарын үзләштерүгә, материалны сайлап алуга һәм системага салуга юнәлдерелгән.

Беренче тема – **«Мин»**. Татар телен белү дәрәҗәсенә карап, игътибар түбәндәге темаларга юнәлтелә: минем яраткан әдәби героем, минем яраткан язучым (шагыйрем), киләчәктәге һөнәрләр, минем мавыгуларым, тирә-юньдәгеләрнең ихтирамы һ.б.

Теманың эчтәлеге тәрбияви бурычлар белән үрелеп бара, телдән һәм язма сөйләмне үстерүгә юнәлтелгән.

Икенче тема – **«Тирә-як, көнкүреш»**. Түбәндәге темаларга басым ясала: мин яшәгән төбәкнең табигате, минем гаиләнең шәҗәрәсе, торак пунктлар, минем төбәкнең географик объектлары һ.б.

Материал әйләнә-тирә дөнья белән танышуга, аерым күренешләргә мөнәсәбәт формалаштыруга, укучыларның дөньяга карашын киңәйтүгә юнәлдерелгән.

Өченче тема – **«Туган җирем»**. Тема Россиянең тарихы, мәдәнияте, тормыш үзенчәлекләре, истәлекле урыннары һ.б. белән таныштыруны максат итеп куя.

Материал толерантлык, күпмилләтле, күпмәдәниятле җәмгыятьтә бер-береңне хөрмәт итү принциплары нигезендә Россия гражданлык җәмгыяте төзү бурычларына җавап бирердәй шәхес сыйфатларын тәрбияләүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән.

Дүртенче тема – **«Татар дөньясы»**. Игътибар түбәндәге темаларга юнәлтелә: татар йорты, милли киемнәр, бизәкләр, татар халкының гореф-гадәтләре һ.б.

Тема гражданлык позициясен һәм милли-мәдәни бердәмлекне формалаштыруга, шулай ук татар мәдә-

ниятен дөнья мәдәнияте контекстында кабул итә белүгә юнәлдерелгән.

## Сөйләм эшчәнлеге төрләре

**Тыңлау**

Текстны, күләмле әсәрне ишетеп аңлау. Аудио- һәм видеотекстларның төп эчтәлеген ишетү һәм аңлау. Төрле функциональ-мәгънәви сөйләм төрләренә караган, тыңланган һәм укылган текстларның эчтәлеген аңлау. Текстны сөйләм әсәре буларак аңлау, аның төзелешен, абзацларга бүленеш үзенчәлекләрен ачыклау.

**Сөйләү**

Укучыларның интонация күнекмәләрен камилләштерү – эмоциональ һәм мәгънәви интонацияне аеру. Төрле темаларга багышланган диалогларда, әңгәмәләрдә, бәхәсләрдә катнашу.

Монологның (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү) һәм диалогның (өндәү, фикер алышу, шәхесара мөнәсәбәтләрне билгеләү һәм җайга салу) төрле төрләрен белү. Тәкъдим ителгән аралашу ситуациясеннән чыгып, кыскача фикер әйтү.

Текст төзелеше нормаларын саклап (логикага нигезләнү, эзлеклелек, темага туры килү, бәйләнеш), үз фикерләрен телдән һәм язма формада ирекле, дөрес итеп әйтеп бирү осталыгы. Сорауларга киңәйтелгән җаваплар бирә белү. Дәрес материалыннан, үрнәктән һәм терәк сүзләрдән, сораулар яки планнан файдаланып, үз текстларыңны төзү. Текстның эчтәлегенә карата сораулар кую һәм аларга җавап бирә белү.

Укылган текстларның эчтәлеген җентекләп һәм кыс-

картып сөйләү. Текстның эчтәлеген сөйләүченең затын үзгәртеп сөйләү. Текст төрен билгеләү (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү) һәм, билгеле бер төргә туры китереп, үз текстыңны төзү. Башкарылган проект эше нәтиҗәләрен татар телендә кыскача бәян итү.

**Уку**

Татар телендә текстларны аңлап, йөгерек һәм сәнгатьле уку. Төрле стиль һәм жанрдагы текстларны уку, укуның төрле төрләрен белү (өйрәнү, танышу, күз йөртеп чыгу). Уку һәм тексттан кирәкле мәгълүматны табу.

Китап, газета һәм журналлар, Интернет чыганаклар белән эшләү. Теманы һәм текстның төп фикерен билгеләү.

**Язу**

Фонетика, лексика һәм грамматикага караган күнегүләрне язмача эшләү. Текст төзелеше нормаларын (логикага нигезләнү, эзлеклелек, темага туры килү, бәйләнеш) саклап, үз фикереңне язма формада иркен һәм дөрес итеп әйтә белү.

Укылган текстның планын төзү. Бирелгән темага үз текстыңны язу. Картина ярдәмендә текст төзү. Үз фикереңне белдергәндә куллану өчен тексттан кыскача күчермәләр язып алу. Төрле чыганаклардан мәгълүмат туплау, лингвистик сүзлекләрдән, белешмә әдәбияттан ирекле файдалану; текстларны мәгълүмати эшкәртү (тезислар, конспектлар, рефератлар, рецензияләр язу).

## Сөйләм эшчәнлеге һәм сөйләм культурасы

Телдән һәм язма сөйләм

Диалогик һәм монологик сөйләм

Текст белән эш

**Фонетика, графика**
Сингармонизм законы
Тартык авазлар
Сузык авазлар
Иҗек. Иҗек төрләре
Басым. Интонация
Фонетик анализ
Сөйләм органнары

**Орфоэпия**
Татар теленең орфоэпиясе турында төшенчә

**Лексикология**
Сүзнең лексик мәгънәсе
Һөнәри лексика
Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар
Искергән сүзләр. Тарихи сүзләр
Алынма сүзләр
Неологизмнар
Фразеологизмнар

**Морфемика һәм сүз ясалышы**
Сүзнең тамыры. Кушымчалар. Сүзнең нигезе
Татар телендә сүз ясалыш ысуллары

**Морфология**
Сүз төркемнәре
Исем сүз төркеме
Сыйфат сүз төркеме

Алмашлык
Сан сүз төркеме
Фигыль. Заман категориясе
Хәзерге заман хикәя фигыль
Үткән заман хикәя фигыль
Киләчәк заман хикәя фигыль
Ярдәмче фигыльләр
Рәвеш
Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр
Кисәкчәләр
Теркәгечләр
Тезүче теркәгечләр

**Синтаксис**
Җөмләнең баш кисәкләре
Тиңдәш кисәкләр
Җөмләнең иярчен кисәкләре
Җәенке һәм җыйнак җөмләләр
Ия һәм хәбәрнең белдерелүе

## УКУ ПРЕДМЕТЫН ҮЗЛӘШТЕРҮНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ СИСТЕМАСЫ

Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешүне бәяләү системасы белем бирүнең сыйфатын тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм бәяләү эшчәнлегендә укытучының да, укучыларның да катнашуын күздә тота.

5 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләүнең төп критерие булып, 5 нче

сыйныфта программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр тора.

Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне бәяләү системасы белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләүгә, укучыларда формалаштырылырга тиешле өч төркем белем нәтиҗәләрен (шәхси, метапредмет, предмет) бәяләргә мөмкинлек бирә торган комплекслы якын килүне күз алдында тота.

**Тыңлау**

Аудиотекстның төрен истә тотып, укучының тыңланган текстның эчтәлеген аңлау сәләте, теманы, төп фикерне аерып күрсәтә белүе тикшерелә. Моннан тыш, төп һәм икенчел мәгълүматны аера белүе, тыңланган текстның эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирә белүе, кыскача төп эчтәлекне тапшыра алуы бәяләнә.

Әгәр тыңлауга куелган максатларга тулысынча ирешелгән булса, «5» ле билгесе куела: укучы тыңланган текстларның төп эчтәлеген аңлый, сорауларга тулы күләмдә җавап бирә, теманы, төп фикерне, текст төрен, икенчел фактларны төшереп калдырып, төп фактларны аерып чыгара, терәк сүзләрне дөрес билгели; төп эчтәлекне татар телендә кыскача тапшыра, төп фактларны текстта бирелгән эзлеклелектә санап чыга ала.

Тыңлауның максатына ирешелгән, әмма тулы күләмдә булмаган очракта «4» ле билгесе куела: укучы текстларның төп эчтәлеген аңлый, сорауларга җавап биргәндә, аерым детальләргә/фактларга кагылышлы 1–2 хата җибәрә; теманы һәм төп фикерне билгеләү осталыгын күрсәтә, ләкин төп фикерне аерып күрсәт-

кәндә 1–2 хата бар, текстның төп эчтәлеген җиткерә, ләкин текстны мәгънәви өлешләргә бүлгәндә кыенлыклар булганлыгы күзәтелә.

Тыңлауның максаты өлешчә үтәлгән булса, «3» ле билгесе куела: аудиотекстның мәгънәсе чикләнгән күләмдә аңлашылган. Текст төрен һәм төп теманы билгеләү күнекмәләре формалашмаган.

Бирем үтәлмәгән, тыңлауның максатына ирешелмәгән, тема һәм эчтәлекне укучы аңламаган булса, «2» ле билгесе куела: укучы текстны әһәмияте һәм мәгълүматлылыгы күзлегеннән чыгып бәяли алмый. Мәгълүмат бөтенләй кабул ителми диярлек.

**Сөйләү**

Укучыларның телдән җаваплары монологик һәм диалогик форманы күздә тота.

Диалогик сөйләм ике яки берничә зат арасында турыдан-туры фикер алышу формасын тәшкил итә.

Диалогик сөйләмнең үзенчәлекләре:

- кыска фикерләр;
- паралингвистик (телдән тыш) аралашу чараларын куллану (мимика, ишарәләр);
- интонациянең аерым роле;
- тулы булмаган җөмләләр булу;
- күп өлеше гади җөмләләрдән тора.

Монологик сөйләм – бер яки берничә әңгәмәдәшенә (шул исәптән үзенә дә) юнәлгән сөйләм формасы. Монологик сөйләмнең үзенчәлекләре:

- әйтелгән фикернең тематик эчтәлеген киңәйтеп, тулырак чагылдыруга омтылыш;

- тулыландырылган җәенке җөмләләр куллану.

Укучы тел төшенчәләренә дөрес билгеләмә биргән, материалны аңлаган, үз фикерен нигезләгән, алган белемнәрен практикада кулланган, чыгышын, текстын мөстәкыйль төзегән, тиешле мисаллар китергән, материалны эзлекле һәм, татар әдәби теле нормалары күзлегеннән чыгып, дөрес итеп бәян иткән очракта «5» ле билгесе куела.

Укучы «5» ле билгесенә куелган таләпләргә туры китереп җавап биргән, әмма үзе төзәтерлек 1–2 хата җибәргән һәм бәян ителгәннең эзлеклелегендә һәм сөйләмендә 1–2 җитешсезлек булган очракта «4» ле билгесе куела.

Укучы теманы белгән һәм аңлаган, әмма материал тулы булмаган һәм кагыйдәләрне куллануда төгәлсезлекләр булган; үз фикерен тиешле дәрәҗәдә тирән һәм дәлилле итеп нигезли, үз мисалларын китерә алмаган, материал эзлексез рәвештә бәян ителгән һәм сөйләмендә хаталар булган очракта «3» ле билгесе куела.

Укучының өйрәнгән материалның күп өлешен белмәве ачыкланган, билгеләмәләр һәм кагыйдәләрне куллануда хаталар җибәргән, мәгънәләре бозылган, материал эзлексез һәм икеләнеп бәян ителгән очракта «2» ле билгесе куела.

«5», «4», «3» билгеләре бер җавап өчен генә түгел (укучының әзерлеген тикшерүгә билгеле бер вакыт бирелә), ә билгеле бер вакыт аралыгында, ягъни дәрес барышында алынган җаваплар суммасы өчен дә куелырга мөмкин.

**Уку**

Туган тел (татар теле) дәресендә укуны оештырганда түбәндәге моментлар исәпкә алына:

- укуга керешкәнче, укучылар алдына төгәл формалаштырылган коммуникатив бурычлар куелырга тиеш (текст ни өчен, нинди максат белән укыла);
- куелган бурыч уку төрен сайлауны билгеләгәнлектән, укытучыга укуның теге яисә бу алымнарын үзләштерүне тәэмин итә торган махсус эш башкарырга кирәк;
- укытучы укуның бурычларына һәм төренә туры килә торган контроль формалары табарга тиеш.

Татар теле дәресләрендә текст укуны дөрес оештыру бик мөһим гомумуку күнекмәләрен үстерүгә ярдәм итә: текстны мәгънәви кисәкләргә бүлә белү, алар арасындагы бәйләнешләрне билгеләү, тел һәм сөйләм фактлары һәм күренешләре арасындагы сәбәпләрне ачыклау, терәк сүзләрне (җөмләләрне) табу, бәян ителә торган фактларны төркемләү, текстта ориентлашу, куелган бурычны исәпкә алып, текстның эчтәлеген сөйләү, текстның логик төзелешен билгеләү һ.б.

Тексттан тиешле мәгълүматны алу максаты белән уку (күз йөртеп чыгу):

әгәр укучы кыска вакыт арасында текстны яки берничә өзекне тикшереп, кирәкле мәгълүматны үзләштерсә, «5» ле билгесе куела;

әгәр укучы кыска вакыт арасында кирәкле мәгълүматның 2/3 өлешен кабул итсә, «4» ле билгесе куела;

әгәр укучы кыска вакыт эчендә кирәкле мәгълүматның 1/3 өлешен үзләштерсә, «3» ле билгесе куела;

укучы кыска вакыт эчендә кирәкле мәгълүматны таба алмаса, «2» ле билгесе куела.

Төп эчтәлекне аңлау максаты белән уку (танышу максаты белән уку):

укучы текстның төп эчтәлегенә төшенгән, контексттан чыгып, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен аңлаган, төп фикерне, төп фактларны билгеләгән очракта «5» ле билгесе куела;

укучы текстның төп эчтәлеген аңласа, төп фикерне, төп фактларны ачыкласа, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен аңламыйча, сүзлеккә мөрәҗәгать итсә, уку темпы акрын булса, «4» ле билгесе куела;

укучы текстның төп эчтәлеген өлешчә аңлаган, төп фактларны бик аз күләмдә билгеләгән очракта «3» ле билгесе куела;

укучы текстның төп эчтәлеген аңламаса яки дөрес аңламаса, төп фактларны тапмаса, таныш булмаган лексиканың мәгънәсен аңлатып бирә алмаса, «2» ле билгесе куела.

Текстның төп эчтәлеген мөмкин кадәр тулырак аңлау максаты белән уку (өйрәнү өчен уку):

укучы текстның эчтәлеген тулысынча аңлаган, текстның төп эчтәлеген аңлау өчен барлык мөмкинлекләрдән файдаланган булса, «5» ле билгесе куела;

укучы текстның төп эчтәлеген тулысынча аңлаган булса, ләкин күп тапкырлар сүзлеккә мөрәҗәгать итсә, «4» ле билгесе куела;

укучы текстның эчтәлеген ахыргача аңлап бетермәсә, күп тапкырлар сүзлеккә мөрәҗәгать итсә, «3» ле билгесе куела;

укучы текстның эчтәлеген аңламаса, сүзлектән та-

ныш булмаган сүзләрне таба алмаса, «2» ле билгесе куела.

**Язу**

**Диктант**

Диктант – укучыларны орфографиягә, пунктуациягә, стилистикага һәм язма сөйләмгә өйрәтүнең төп формаларыннан берсе. Диктант укучыларның игътибарын үстерә, фикерләү сәләтен арттыра, үзтикшерүгә өйрәтә. Диктант өчен бәйләнешле текстлар куллану максатка ярашлы. Алар хәзерге татар әдәби теле нормаларына җавап бирергә тиеш.

Диктант текстының якынча күләме: 5 нче сыйныф – 30–40 сүз; 6 нчы сыйныф – 40–50 сүз; 7 нче сыйныф – 50–60 сүз; 8 нче сыйныф – 60–70 сүз; 9 нчы сыйныф – 70–80 сүз.

5 нче сыйныф – 40–50 сүз; 6 нчы сыйныф – 60–70 сүз; 7 нче сыйныф – 80–90 сүз; 8 нче сыйныф – 100–110 сүз; 9 нчы сыйныф – 120–130 сүз.

Хаталары булмаган, язу таләпләренә туры китереп башкарылган эш өчен «5» ле билгесе куела.

1 орфографик һәм 1 пунктуацион хата яки 1 орфографик хата һәм 2 пунктуацион хата булса, «4» ле билгесе куела.

4 орфографик, 2 пунктуацион хата, яки 3 орфографик, 4 пунктуацион хата, яки 7 пунктуацион хата булса, «3» ле билгесе куела.

6 орфографик һәм 6 пунктуацион хата яки 5 орфографик һәм 7 пунктуацион хата булса, «2» ле билгесе куела.

Искәрмә: әгәр диктантка өстәмә грамматик бирем тәкъдим ителсә, текстның күләме 10–15 сүзгә киметелә һәм ике билге куела.

Өстәмә бирем өчен түбәндәге билгеләр куела:

барлык биремнәр дөрес үтәлгән булса, «5» ле билгесе куела;

биремнең 2/3 өлеше дөрес үтәлгән булса, «4» ле билгесе куела;

әгәр биремнәрнең яртысы дөрес үтәлгән булса, «3» ле билгесе куела;

биремнәрнең 1/3 өлеше генә дөрес үтәлгән очракта «2» ле билгесе куела.

**Контроль диктант**

Контроль диктант текстына орфографик һәм пунктуацион кагыйдәләргә караган 2–3 сүз кертелергә тиеш.

Контроль диктант текстына кертелгән орфограммалар 2–3 дәрестә ныгытылган булырга тиеш.

1 чирек ахырына кадәр (5 нче сыйныфта яртыеллык ахырына кадәр) диктантның күләме алдагы сыйныфтагы күләмгә туры килергә тиеш.

Диктантны тикшергәндә түбәндәге хаталар исәпкә алынмаска тиеш:

- мәктәп программасына кертелмәгән кагыйдә;
- өйрәнелмәгән кагыйдә.

Диктантны тикшергәндә бер типтагы хаталарны бер хата дип санарга мөмкин.

Әгәр контроль диктантта 5 төзәтү булса, билге 1 баллга төшә. Әгәр 3 һәм аннан да күбрәк төзәтүләр булса, «5» ле билгесе куелмый.

Контроль диктант өчен текстның якынча күләме:

5 нче сыйныф – 40–45 сүз; 6 нчы сыйныф – 55–60 сүз; 7 нче сыйныф – 65–70 сүз; 8 нче сыйныф – 75 –80 сүз; 9 нчы сыйныф – 90–100 сүз.

5 нче сыйныф – 45–55 сүз; 6 нчы сыйныф – 65–75 сүз; 7 нче сыйныф – 85–95 сүз; 8 нче сыйныф – 105–115 сүз; 9 нчы сыйныф – 125–135 сүз.

Контроль диктантка бер билге куела:

хатасыз яки тупас булмаган 1 орфографик яки 1 пунктуацион хаталы эшкә «5» ле билгесе куела;

2 орфографик һәм 2 пунктуацион хата, яки 1 орфографик хата һәм 3 пунктуацион хата, яки 4 пунктуацион хата, яки 3 орфографик хата булса, «4» ле билгесе куела;

4 орфографик һәм 3 пунктуацион хата, яки 3 орфографик һәм 5 пунктуацион хата, яки 7 пунктуацион хата булса, «3» ле билгесе куела;

7 орфографик һәм 7 пунктуацион хата, яки 6 орфографик һәм 8 пунктуацион хата, яки 5 орфографик һәм 9 пунктуацион хата, яки 8 орфографик һәм 6 пунктуацион хата булса, «2» ле билгесе куела.

**Сүзлек диктанты**

Сүзлек диктанты авыр орфограммалы сүзләрне язуда укучыларның орфографик осталыгын тикшерү максатыннан укытучы ихтыяры белән чиреккә 1 тапкыр үткәрелә.

Сүзлек диктанты өчен сүзләрнең якынча күләме:

5 нче сыйныф – 15–20 сүз; 6 нчы сыйныф – 20–22 сүз; 7 нче сыйныф – 22–24 сүз; 8 нче сыйныф – 24–26 сүз; 9 нчы сыйныф – 26–28 сүз.

5 нче сыйныф –20–22 сүз; 6 нчы сыйныф – 22–24 сүз; 7 нче сыйныф – 24–26 сүз; 8 нче сыйныф – 26–28 сүз; 9 нчы сыйныф – 28–30 сүз.

Сүзлек диктантына түбәндәге билгеләр куела:

«5» ле билгесе хаталары булмаган эш өчен куела;

«4» ле билгесе 2–3 хата җибәрелгән эш өчен куела;

«3» ле билгесе 3–5 хата җибәрелгән эшкә куела;

«2» ле билгесе 6 хата җибәрелгән эшкә куела.

**Сочинение**

Сочинениедә укучылар түбәндәге белем һәм күнекмәләрен күрсәтергә тиеш: планны дөрес төзергә (эчтәлек һәм стилистика күзлегеннән чыгып); сочинениенең темасын тулысынча һәм ахырына кадәр ачарга; үз фикерләрен фактлар ярдәмендә дөрес һәм ышандырырлык итеп бәян итәргә.

Сочинениене тикшергәндә эчтәлек, төзелеш, сүзлек запасы, грамматик һәм орфографик кагыйдәләрне дөрес файдалану һ.б. шуның кебек элементларга игътибар итәргә кирәк. Шулай ук теманы тулысынча ачуга, материалны дөрес файдалануга, раслаучы фактларның булу/булмавына, күпсанлы кабатлауларга да игътибар бирү сорала.

Сочинениенең төзелеше төгәл, эзлекле булырга, вакыйгалар арасында үзара бәйләнеш сакланырга тиеш.

Укучының язма сөйләм телен анализлаганда тел чараларын куллануга игътибар итәргә кирәк.

Сочинениеләрдә сүзләрнең якынча күләме:

5 нче сыйныф – 50–60 сүз; 6 нчы сыйныф – 60–70 сүз; 7 нче сыйныф – 70–80 сүз; 8 нче сыйныф – 80–90 сүз; 9 нчы сыйныф – 90–100 сүз.

5 нче сыйныф – 60–80 сүз; 6 нчы сыйныф – 80–100 сүз; 7 нче сыйныф – 100–120 сүз; 8 нче сыйныф – 120–140 сүз; 9 нчы сыйныф – 140–160 сүз.

Сочинение өчен 2 билге куела: эчтәлеге һәм грамоталылык өчен.

Эчтәлеге өчен:

тема тулысынча ачылган, темага карата шәхси мөнәсәбәт күрсәтелгән, лексик материал уңышлы сайланган очракта «5» ле билгесе куела;

тематик материалны яхшы белү күзәтелсә, фикерләү, гомумиләштерү һәм нәтиҗәләр дөрес ясалса, эш дөрес әдәби телдә язылса, «4» ле билгесе куела;

эш темага туры килсә дә, җаваплар схема рәвешендә генә бирелсә, материал бәян ителгәндә кайбер төгәлсезлекләр булса, бәян итүнең эзлеклелеге бозылса, «3» ле билгесе куела;

сочинение темасы ачылмаса, «2» ле билгесе куела.

Грамоталылык өчен:

әгәр эш орфографик һәм пунктуацион яктан дөрес һәм хатасыз башкарылса, «5» ле билгесе куела;

2–3 стилистик хата, 3 тән дә артык булмаган орфографик һәм 3 пунктуацион хата булса, «4» ле билгесе куела;

3–4 стилистик хата һәм 6 дан да артык булмаган орфографик һәм пунктуацион хата җибәрелсә, «3» ле билгесе куела;

5–6 стилистик хата һәм 6 дан артык орфографик һәм пунктуацион хаталы эшкә «2» ле билгесе куела.

**Изложение**

Изложение тексты белем һәм тәрбия бирү бурычла-

рына җавап бирергә, эчтәлеге һәм теле укучыларга аңлаешлы булырга тиеш.

5 нче сыйныфта изложение тексты өчен зур булмаган хикәя яисә әдәби әсәрдән алынган өзек сайлана. Текст аңлаешлы булырга, авторлык аңлатмалары белән тәэмин ителергә, геройның позициясе, анын кичерешләре төгәл күрсәтелергә тиеш. 5–6 нчы сыйныфларга изложение тексты буларак кечкенә характеристикалар, хикәяләү тибындагы текстлар, әдәби әсәрләрдән алынган өзекләр тәкъдим итәргә мөмкин. 7–9 нчы сыйныфларда диалоглар һәм фикер йөртүләр белән катлауландырылган характеристикалар тәкъдим ителә.

Изложениеләрдә сүзләрнең якынча күләме:

5 нче сыйныф – 55–65 сүз; 6 нчы сыйныф – 65–75 сүз; 7 нче сыйныф – 75–85 сүз; 8 нче сыйныф – 85–95 сүз; 9 нчы сыйныф – 95–105 сүз.

5 нче сыйныф –65–75 сүз; 6 нчы сыйныф – 75–85 сүз; 7 нче сыйныф –85–95 сүз; 8 нче сыйныф – 95–105 сүз; 9 нчы сыйныф – 105–115 сүз.

Изложениене бәяләгәндә түбәндәгеләргә игътибар итү сорала: текстның эчтәлеген аңлау дәрәҗәсе; текстның эчтәлеге ни дәрәҗәдә ачылу; төп фикернең эзлеклелеге һәм текстның өлешләре арасындагы бәйләнеш; сүзләрне дөрес сайлау, җөмләләрне дөрес төзү, җөмләләрдә сүзләрнең тәртибе һәм бәйләнеше, төрле җөмләләрне куллану, туры һәм кыек сөйләм белән җөмләләр төзү; укучының язма сөйләм теленең камиллеге (сүз, җөмлә төрләре, сүзлек запасыннан дөрес

файдалану); орфографик һәм пунктуацион хаталар булу/булмау.

Изложение өчен ике билге куела: эчтәлеге һәм грамоталылыгы өчен.

Эчтәлеге өчен:

автор текстына якын итеп, дөрес һәм эзлекле рәвештә язылса, «5» ле билгесе куела;

фикерләрне бәян итүдә бераз эзлеклелекнең сакланмавы сизелгән, 1–2 фактик хата һәм сөйләм төгәлсезлекләре булган эшкә «4» ле билгесе куела;

автор текстыннан кайбер тайпылышлар, фикерләрне бәян итү эзлеклелегендә 2–3 җөмлә төзелешендә хаталар күзәтелсә, сүз байлыгы ярлы булса, «3» ле билгесе куела;

автор текстыннан шактый тайпылышлар, мөһим эпизодларны, төп фикерне, төп өлешне һ.б. төшереп калдырулар булса, фикерләрне бәян итү эзлеклелеге бозылса, текстның өлешләре, аерым җөмләләр арасында бәйләнеш булмаса, сүз байлыгы ярлы булса, «2» ле билгесе куела.

Грамоталылык өчен:

орфографик һәм пунктуацион хаталар булмаса, «5 » ле билгесе куела. 1–2 төзәтү рөхсәт ителә;

орфографик хатасы икедән дә артык булмыйча, бер пунктуацион хата булган һәм 1–2 төзәтүле эшкә «4» ле билгесе куела;

3–5 орфографик, 1–2 пунктуацион хаталы һәм 1–2 төзәтүле эшкә «3» ле билгесе куела;

6 һәм аннан да күбрәк орфографик, 3–4 пунктуацион хаталы һәм 3–4 төзәтүле эш өчен «2» ле билгесе куела.

**Тест**

5–9 нчы сыйныфларда өйрәтү яки тикшерү максатыннан тест үткәрелергә мөмкин. Укытучы ихтыяры белән тест теге яки бу темага җайлаштырыла.

Тестны тикшергәндә түбәндәге билгеләр куела:

барлык биремнәр дә дөрес үтәлгән булса, «5» ле билгесе куела;

биремнең 2/3 өлеше дөрес үтәлгән булса, «4» ле билгесе куела;

әгәр биремнәрнең яртысы дөрес үтәлгән булса, «3» ле билгесе куела;

биремнең 1/3 өлеше генә дөрес үтәлгән яки бөтенләй үтәлмәгән булса, «2» ле билгесе куела.

**Проект эше**

5–9 нчы сыйныфларда проект эшчәнлеге белем бирүнең аерылгысыз өлеше булып тора. Ул уку эшчәнлегенең мотивациясен һәм нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итә. Бәяләү критерийлары (баллар буенча):

1) сайланган теманы нигезләү, формалаштырган тема эчтәлегенең куелган максатларга һәм бурычларга туры килүе (1 дән 3 баллга кадәр);

2) грамоталы чыгыш (0 дән 2 баллга кадәр);

3) чыгыш ясауның сыйфаты, материалны белүе (1 дән 3 баллга кадәр);

4) проектны тәкъдим итү сыйфаты (1 дән 3 баллга кадәр);

5) бәхәс оештыра белү, үз идеяләреңне дөрес яклый белү (0 дән 3 баллга кадәр);

6) өстәмә балл (креативлык өчен) – 1 балл.

Барлыгы – 15 балл.

«5» ле билгесе укучы 12 дән 15 кә кадәр балл җыйган очракта куела.

«4» ле билгесе укучы 10 нан 12 гә кадәр балл җыйган очракта куела.

«3» ле билгесе укучы 7 дән 10 га кадәр балл җыйган очракта куела.

«2» ле билгесе укучы 7 дән да кимрәк балл җыйган очракта куела.

**Эш төрләре һәм аларның сыйныфлар буенча саны**

| Эш төрләре | 5 нче сыйныф | 6 нчы сыйныф | 7 нче сыйныф | 8 нче сыйныф | 9 нчы сыйныф |
|---|---|---|---|---|---|
| Сүзлек диктанты | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| Диктант | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Контроль диктант | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Изложение | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Сочинение | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Тест | 2 | 2 | 2 | 3 | 3 |
| Проект эше | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Барлыгы | 14 | 14 | 14 | 15 | 15 |

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ[1]

| Блоклар | Дәреснең темасы | Сәгатьләр саны | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә бәяләмә |
|---|---|---|---|
| **5 нче сыйныф** | | | |
| Сөйләм эшчәнлеге һәм сөйләм культурасы | Телдән һәм язма сөйләм | 1 | Телдән һәм язма сөйләмнең аермасын аңлау.<br>Тел һәм сөйләм төрләре, сөйләм формалары: диалог һәм монологлар турындагы төшенчәне формалаштыру.<br>Сөйләм культурасы төшенчәсен; татар теленең сөйләм этикетын формалаштыру.<br>Монолог (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү) һәм диалог (өндәү, фикер алышу, шәхесара мөнәсәбәтләрне билгеләү һәм җайга салу) төзү.<br>Текст эчтәлегенә караган сораулар формалаштыру һәм аларга җавап бирү.<br>Дәрес материалы, үрнәк, терәк сүзләр, сораулар яки планнан файдаланып, үз текстларын төзү. |
| | Диалогик һәм монологик сөйләм | 1 | |
| | Текст белән эш | 4 | |

[1] Кара хәрефләр белән бирелгән материал ике юнәлешкә дә, зәңгәр төс белән бирелгәне тирәнтен өйрәнүчеләргә генә карый.

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Сөйләмнең төрле функциональ-мәгънәви типларына караган тыңланган һәм укылган текстларның эчтәлеген аңлау.<br>Татар телендәге текстларны йөгерек, аңлап һәм сәнгатьле итеп уку.<br>Язмача фонетик, лексик һәм грамматик күнегүләр эшләү.<br>Текст төзү нормаларын (логикага нигезләнү, эзлеклелек, темага туры килү, бәйләнеш) саклап, телдән һәм язма формада үз фикерләреңне дөрес итеп бәян итү.<br>Уку процессында һәм көнкүреш шартларында сөйләм этикеты нормаларын үтәү.<br>Интонацияне саклау, тел чараларын дөрес сайлау һәм оештыру, үз сөйләмеңне контрольдә тоту. |
| «Мин»<br>14 / 1 | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Фонетика, графика | Сингармонизм законы. Орфография | 2 | Сингармонизм законын белү: ирен һәм рәт гармониясен аеру. Сүзләрне дөрес язу һәм әйтү.<br>Сөйләм аппаратының төзелешен аңлау.<br>Тартык һәм сузык авазларны танып белү.<br>Телдән һәм транскрипция элементлары ярдәмендә сөйләмнең аерым авазларын анализлау һәм характерлау, [э], [ц], [щ] авазларын, аларны язуда белдерә торган хәрефләрне дөрес куллану.<br>Ике аваз белдерә торган хәрефләрне: е, ё, ю, я дөрес язу.<br>Ачык һәм ябык иҗекне билгеләү.<br>Басымлы иҗекне, логик басымны билгеләү.<br>Дөрес интонация белән төрле җөмләләр уку.<br>Боерык һәм тойгылы җөмләләрне танып белү.<br>Сүзгә фонетик анализ ясау. |
| | Сөйләм органнары | 1 | |
| | Татык авазлар | 3 | |
| | Сузык авазлар | 2 | |
| | Изложение | 1 | |
| | Иҗек. Иҗекләрнең төре | 1 | |
| | Басым. Интонация | 2 | |
| | Фонетик анализ | 1 | |
| | Диктант | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Орфоэпия | Татар теленең орфоэпиясе турында төшенчә | 1 | Авазлар һәм авазлар тезмәсен әйтү, хәзерге татар әдәби теле нормалары нигезендә сүзләрнең басымын билгеләү. |
| «Тирә-як, көнкүреш» 13 / 4 | | | |
| Лексикология | Сүзнең лексик мәгънәсе | 1 | Сүзнең лексик мәгънәсен ачыклау.<br>Һөнәри лексиканы белү.<br>Сөйләмдә синонимнар, антонимнар, омонимнар куллану.<br>Лексик омонимнарны, омофоннарны, омографларны, омоформаларны билгеләү.<br>Искергән, тарихи сүзләрне, неологизмнарны (иң гади очракларын) белү.<br>Алынмаларны һәм гомумтөрки чыгышлы сүзләрне аеру.<br>Фразеологизмнарны сөйләмдә куллану, аларның мәгънәсен ачыклау. |
| | Һөнәри лексика | 1 | |
| | Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар | 3 | |
| | Искергән һәм тарихи сүзләр | 1 | |
| | Алынма сүзләр | 2 | |
| | Проект эше | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Неологизмнар | 1 | |
| | Фразеологизмнар | 2 | |
| Морфемика һәм сүз ясалышы | Сүзнең тамыры. Кушымчалар. Сүзнең нигезе | 3 | Сүзнең тамырын, кушымчасын, нигезен билгеләү.<br>Форма ясагыч һәм сүз ясагыч кушымчаларны аеру.<br>Татар телендә сүз ясалышы ысулларын аеру.<br>Сүзләргә морфемик һәм сүз ясалышы ягыннан анализ ясау. |
| | Татар телендә сүз ясалыш ысуллары | 1 | |
| | Изложение | 1 | |
| «Туган җирем» 21/2 | | | |
| Морфология | Сүз төркемнәре | 1 | Сүз төркемнәрен билгеләү: мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Исем | 4 | Исемнең гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү, аның сөйләмдәге ролен аңлату.<br>Тамыр, ясалма, кушма, парлы һәм тезмә исемнәрне танып белү.<br>Исемнәрдә тартым категориясен белү.<br>Сыйфатның гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү, аның сөйләмдәге ролен аңлату.<br>Сыйфатларның чагыштырма, артыклык, кимлек дәрәҗәсен ясау.<br>Тамыр, ясалма, кушма, парлы һәм тезмә сыйфатларны белү.<br>Алмашлыкның гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү.<br>Зат алмашлыкларының мәгънәсен, сөйләмдә кулланылышын билгеләү. |
| | Сыйфат | 3 | |
| | Алмашлык | 2 | |
| | Сан | 2 | |
| | Фигыль. Заман категориясе | 1 | |
| | *Контроль диктант* | 1 | |
| | Хәзерге заман хикәя фигыль | 1 | |
| | Үткән заман хикәя фигыль | 2 | |
| | Киләчәк заман хикәя фигыль | 2 | |
| | Ярдәмче фигыльләр | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Рәвеш | 1 | Зат һәм күрсәтү алмашлыкларын килешләр белән төрләндерү.<br>Күрсәтү алмашлыкларын танып белү.<br>Микъдар һәм тәртип саннарының гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү.<br>Микъдар саннарын килешләр белән төрләндерү.<br>Тамыр, кушма, парлы һәм тезмә саннарны дөрес язу һәм ясау.<br>Хикәя фигыльнең гомуми грамматик мәгънәсен, морфологик билгеләрен һәм синтаксик функцияләрен билгеләү, сөйләмдәге ролен аңлату.<br>Фигыльнең заман формаларын ясау.<br>Хәзерге, үткән (билгеле һәм билгесез) һәм киләчәк (билгеле һәм билгесез) заман хикәя фигыльләрне барлык һәм юклыкта төрләндерү. |
| | *Сочинение* | 1 | |
| | *Текст* | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Сөйләмдә ярдәмче фигыльләрне дөрес куллану.<br>Рәвешләрнең гомуми грамматик мәгънәсен билгеләү. Аларның сөйләмдә кулланышын аңлату.<br>Рәвешләрнең төркемчәләрен (урын, вакыт) танып белү. |
| **«Татар дөньясы»**<br>**14 /3** | | | |
| Морфология | Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр | 2 | Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләрне билгеләү.<br>Бәйлекләрне төрле килеш формаларындагы сүзләр белән куллану. |
| | Кисәкчәләр | 1 | Кисәкчәләрне танып белү.<br>Кисәкчәләрне дөрес язу. |
| | Теркәгечләр | 1 | Теркәгечләрне танып белү. Тезүче теркәгечләре аера белү. |
| | Тезүче теркәгечләр | 1 | Теркәгечләр белән җөмләләр төзү.<br>Өйрәнелгән сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Синтаксис | Җөмләнең баш кисәкләре | 2 | Җөмләнең баш кисәкләре – ия һәм хәбәрне табу.<br>Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аеру.<br>Тиңдәш кисәкләрне табу һәм, мөстәкыйль рәвештә, тиңдәш кисәкләр белән җөмләләр төзү.<br>Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә санау интонациясен куллану.<br>Җәенке һәм җыйнак җөмләләрне танып белү.<br>Җөмләнең баш кисәкләре кайсы сүз төркемнәре белән белдерелүен билгеләү. |
| | *Проект эше* | 1 | |
| | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | 1 | |
| | Җөмләнең иярчен кисәкләре | 3 | |
| | Җәенке һәм җыйнак җөмләләр | 2 | |
| | Ия һәм хәбәрнең белдерелүе | 1 | |
| | *Сочинение* | 1 | |
| | *Тест* | 1 | |

## Дәрес планнары үрнәкләре

### Лексик тема: Яхшылык җирдә ятмый

**5 / 1 сәгать**
**1 дәрес**

**Тема:** Фонетика. Сингармонизм законы.

**Максат һәм бурычлар**: Сөйләм авазлары турында сөйләшү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; уку бурычын дөрес билгеләү; татар теленең фонетикасын, сингармонизм законын өйрәнү.

**Дәрес тибы**: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау**: электрон дәреслек.

**Дәрес этаплары**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**:

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: татар теленең сөйләм авазлары, сингармонизм законы турында сөйләшү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Сөйләм авазлары, сингармонизм законы.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Мәкальләрнең башын ахыры белән тоташтыру (16 күнегү, 19 бит).

2) Теманың эпиграфын уку һәм сорауларга җавап бирү (17 күнегү, 19 бит).

3) Сүзләрне дөрес уку, татар һәм рус телләрендә [о], [ы], [э] авазларының әйтелешенә игътибар итү (18 күнегү, 20 бит).

4) Сүзләрне дөрес уку һәм [а] авазының әйтелешенә игътибар итү (19 күнегү, 20 бит).

5) Текстны уку һәм сорауларга җавап бирү; ирен гармониясенә буйсынган бер сүзне табу һәм транскрипциясен язу; калын әйтелешле [ғ], [қ] авазлары булган сүзләрне табып уку; тексттан кушма исемнәрне язып алу һәм яңгырау тартыклар астына — бер сызык, саңгырау тартыклар астына ике сызык сызу (20 күнегү, 20 – 21 битләр).

6) Текстның дәвамын уку һәм сорауларга җавап бирү; тексттан рәт гармониясенә буйсынган биш сүз табып әйтү; яңгырау тартыклардан торган биш сүз язып алу; саңгырау тартыклардан торган өч сүз табып уку (21 күнегү, 21-1 – 21-3 күнегүләр, 22 бит).

7) Сүзләрнең дөрес язылган транскрипциясен табу (22 күнегү, 23 бит).

8) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 2 дәрес

**Тема:** Татар теленең орфоэпиясе һәм орфографиясе.

**Максат һәм бурычлар**: Татар теленең орфоэпиясе һәм орфографиясе турында сөйләшү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; уку бурычын дөрес билгеләү; сүзләрне дөрес язу һәм әйтү.

**Дәрес тибы**: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау**: электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**:

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: татар теленең орфоэпиясе һәм орфографиясе турында сөйләшү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Татар теленең орфоэпиясе һәм орфографиясе.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Теманың эпиграфы белән кабат эшләү; яхшылыкка караган эш-гамәлләрне табып уку һәм нәтиҗә ясау; җөмләләрне күчереп язу һәм нечкә сузыкларның астына сызу (24 күнегү, 24-1 – 24-3 күнегүләр, 24 бит).

2) Татар алфавитын искә төшерү һәм сорауларга җавап бирү (25 күнегү, 25 бит).

3) Текстны уку һәм сорауларга җавап бирү; тексттан бер хәрефнең ике аваз белдергән очрагына мисаллар табып язу (26 күнегү, 26-1 күнегү, 26 бит).

4) *к, п* тартыкларына тәмамланган сүзләргә сузыкка башланган кушымча өстәп язу (27 күнегү, 26 бит)

5) Сүзләрне алфавит тәртибендә язу (28 күнегү, 26 бит)

6) Квадрат җәяләргә хәрефләр белдергән авазларны язу (29 күнегү, 26 бит).

7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 3 дәрес

### Лексик тема: Гаилә – җылы учак

**Тема:** Сөйләм органнары.

**Максат һәм бурычлар**: Сөйләм аппаратының төзелеше турында сөйләшү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; уку бурычын дөрес билгеләү; татар телендә сөйләм органнарын өйрәнү.

**Дәрес тибы**: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау**: электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**:

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: сөйләм аппаратының төзелешен ачыклау.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Сөйләм органнары.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Башваткычны чишү һәм сорауларга җавап бирү (31 күнегү, 27 бит).

2) Мәкальләрне уку һәм мәгънәләрен аңлату (32 күнегү, 27 бит).

3) Сүзләрнең дөрес язылган транскрипциясен табу (32-1 күнегү, 28 бит).

4) Сөйләм авазларын барлыкка китерүдә кайсы сөйләм органнары катнашуын ачыклау (33 күнегү, 28 бит).

5) Тәрҗемәләрне табу (34 күнегү, 29 бит).

6) Текстны рольләргә бүлеп уку һәм сорауларга җавап бирү; калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны парлап уку; сүзләрне дөрес уку һәм татар телендә [о], [ы], [э], [ө] авазларының әйтелешенә игътибар итү (35 күнегү, 35-1 – 35-4 күнегүләр, 30 бит).

7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 4 дәрес

**Тема:** Тартык авазлар. Аларны белдергән хәрефләр.

**Максат һәм бурычлар**: Тартык авазларны танып белү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; уку бурычын дөрес билгеләү; татар телендә яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аерырга өйрәнү.

**Дәрес тибы**: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау**: электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**:

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: татар телендә яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру үзенчәлекләре турында сөйләшү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Яңгырау һәм саңгырау тартык авазлар.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Шигырьләр ярдәмендә башваткычны чишү һәм сорауларга җавап бирү (37 күнегү, 32 бит).

2) Теманың эпиграфы белән эшләү (38 күнегү, 33 бит).

3) Текстны уку һәм сорауларга җавап бирү; *танышабызмы* сүзендә нинди хәрефләр барлыгын ачыклау (39 күнегү, 39-1 – 39-2 күнегүләр, 33 бит).

4) Текстны уку һәм сорауларга җавап бирү; *гаилә, ку-*

*нак, җыр, күңелле* сүзләрендәге тартык авазларны яңгырау һәм саңгырау тартыкларга аерып язу (40 күнегү, 40-1 күнегү, 35 бит).

5) Текстны уку; текстка исем уйлау; тексттан яңгырау тартыклар гына булган сүзләрне табып язу; төшеп калган сузык авазларны куеп, җөмләне уку (41 күнегү, 41-1 – 41-3 күнегүләр, 35 бит)

6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 5 дәрес

**Тема:** Парлы һәм парсыз тартыклар.

**Максат һәм бурычлар**: Парлы һәм парсыз тартык авазларны танып белү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; уку бурычын дөрес билгеләү; татар телендә парлы һәм парсыз тартык авазларны аерырга өйрәнү.

**Дәрес тибы**: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау**: электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**:

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: татар телендә парлы һәм парсыз тартык авазлар турында сөйләшү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Парлы һәм парсыз тартык авазлар.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Теманың эпиграфын кабат уку һәм сорауларга җавап бирү (43 күнегү, 37 бит).

2) Рәсемне карау һәм нәтиҗә ясау (44 күнегү, 44-1 – 44-2 күнегүләр, 37 бит).

3) Мәкальләрнең башын ахыры белән тоташтыру (45 күнегү, 38 бит).

4) Диалогны рольләргә бүлеп уку һәм сорауларга җавап бирү; диалогик сөйләмне монологик сөйләмгә әйләндерү (46 күнегү, 46-1 күнегү, 38–39 битләр).

5) Текстны уку; сүзләрне алфавит тәртибендә язу (47 күнегү, 47-1 – 47-2 күнегүләр, 39 бит).

6) Рәсемдәге шәҗәрәне карау (48 күнегү, 48-1 – 48-3 күнегүләр, 40–41 битләр).

7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 6 дәрес

**Тема:** [ц], [щ] авазлары һәм аларны белдергән хәрефләр.

**Максат һәм бурычлар**: [ц], [щ] авазлары һәм аларны белдергән хәрефләр турында сөйләшү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; уку бурычын дөрес билгеләү; [ц], [щ] авазлары һәм аларны белдергән хәрефләр белән эшләү.

**Дәрес тибы**: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау**: электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**:

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: [ц], [щ] авазлары һәм аларны белдергән хәрефләр турында сөйләшү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) [ц], [щ] авазлары һәм аларны белдергән хәрефләр.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Шигырь юлларын уку; [ц], [щ] авазлары кергән сүзләр уйлап әйтү (50 күнегү, 50-1 күнегү, 42 бит).

2) Рәсемнәрне карау һәм предметларның исемнәрен әйтү; ике сүз белән җөмлә төзеп язу; диалог ярдәмендә текст төзү (51 күнегү, 51-1 күнегү, 43 бит).

3) Репликалар ярдәмендә дөрес итеп диалог төзү; диалог ярдәмендә текст төзеп язу (52 күнегү, 43 бит).

4) Ситуация белән танышу, фикереңне дәлилли белү (53 күнегү, 44 бит).

5) Теманың эпиграфын искә төшерү һәм сораугa җавап бирү (54 күнегү, 44 бит).

6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

Учебное издание

**Шакурова** Муслима Магесумовна
**Гиниятуллина** Лилия Миннулловна
**Хисамов** Олег Ришатович

**РОДНОЙ ЯЗЫК**
**(татарский язык)**

5 класс

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
основного общего образования
(для изучающих татарский язык как родной)

*Допущено Министерством образования и науки*
*Республики Татарстан*

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Шәкүрова** Мөслимә Мәгъсүм кызы
**Гыйниятуллина** Лилия Миңнулла кызы
**Хисамов** Олег Ришат улы

**ТУГАН ТЕЛ**
**(татар теле)**

5 сыйныф

Методик әсбап
төп гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән*
*министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән*

Редактор *Л.Г. Шарифуллина*
Художник *А.Б. Шляпкин*
Верстка *Э.Ф. Нурмухаметовой*

Подписано в печать с оригинал-макета 4.04.2022.
Формат 60 х 84 1/16.